**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 август 2026 ел № 1085

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында эвакуация чараларын оештыру турында» 2024 елның 07 ноябрендәге 1335 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында эвакуация чараларын оештыру турында» 2024 елның 07 ноябрендәге 1335 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 27 июлендәге 834 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эвакуацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2026 елның 2 мартындагы 216 номерлы ДСП карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының имин районнары территорияләрендә таралучы һәм эвакуацияләнүче халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне кабул итүне, урнаштыруны һәм беренче чиратта тормыш белән тәэмин итүне оештыру турында күрсәтелгән карар белән расланган Нигезләмәдә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эвакуацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2026 елның 2 маендагы 216 номерлы ДСП карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуацияләнүче халыкны урнаштыру өчен билгеләнгән торак пунктлары исемлеген әлеге карар белән расланган яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә.

1.4. Кабул итү эвакуация пункты турында күрсәтелгән карар белән расланган Нигезләмәдә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эвакуацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2026 елның 2 мартындагы 216 номерлы ДСП карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. Күрсәтелгән карар белән расланган эвакуацияләнүче халыкны төшереп калдыру пункты турындагы Нигезләмәдә:

«Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегенең беренче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эвакуацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2026 елның 2 мартындагы 216 номерлы ДСП карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә төзелгән кабул итү эвакуация пунктлары исемлеген әлеге карар белән расланган яңа редакциядә, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында эвакуация чараларын оештыру турында» 2024 елның 07 ноябрендәге 1335 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 27 июлендәге 834 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин